| БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ РАЙОН БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«16» 07 2022 ел № 217

Балтач муниципаль районы территориясендә табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрне бетерү өчен матди ресурслар резервларын булдыру турында

«Халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән яклау турында» 1994 елның 21 декабрендәге 68-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрне бетерү өчен матди ресурслар резервлары булдыру турында» 2008 елның 11 июлендәге 488 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары, Балтач район башкарма комитеты турында нигезләмә нигезендә, Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карар бирә:

1. Расларга:

Балтач муниципаль районы территориясендә табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрне бетерү өчен матди ресурслар резервлары турында нигезләмәне (1 нче кушымта);

Балтач муниципаль районының табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрне бетерү өчен матди ресурслар номенклатурасын һәм күләмен (2 нче кушымта).

2. Балтач муниципаль районы оешмалары һәм учреждениеләре җитәкчеләренә тәкъдим итәргә:

ведомство буйсынуындагы объектларда объект дәрәҗәсендәге табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү өчен матди ресурслар резервларын булдырырга;

объект территориясендә табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрнең нәтиҗәләрен бәяләүдән чыгып, табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрне бетерү өчен матди ресурслар резервының номенклатурасын һәм күләмен билгеләргә.

3. Балтач муниципаль районы территориясендә гадәттән тыш хәлләрне бетерү өчен матди ресурсларның җирле резервын булдыру, саклау, файдалану һәм

аны тулыландыру эшләрен финанслау Балтач муниципаль районы бюджеты акчалары исәбеннән гамәлгә ашырырга.

4. «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы территориясендә табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрне бетерү өчен матди ресурслар резервларын булдыру турында» 2016 елның 16 маендагы 132 номерлы Балтач район башкарма комитеты карары үз көчен югалткан дип таныйрга.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http:pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Балтач муниципаль районының рәсми сайтында халыкка җиткерергә.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасарына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балтач район башкарма комитеты
җитәкчесе А.Ф. Хәйретдинов

Татарстан Республикасы
Балтач район башкарма комитетының
2022 елның «16» 07
217 номерлы карарына
1 нче кушымта

Балтач муниципаль районы территориясендә табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрне бетерү өчен матди ресурслар резервлары турында
НИГЕЗЛӘМӘ

I. Гомуми нигезләмәләр

1. Әлеге Нигезләмә «Халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән яклау турында» 1994 елның 21 декабрендәге 68-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрне бетерү өчен матди ресурслар резервлары булдыру турында» 2008 елның 11 июлендәге 488 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә эшләнгән.

2. Гадәттән тыш хәлләрне бетерү өчен матди ресурслар резервлары гадәттән тыш хәлләр барлыкка килгән очракта кирәкле чараларны ашыгыч рәвештә җәлеп итү максатларында алдан ук төзелә һәм азык-төлек, азык чималы, медицина мөлкәте, медикаментлар, төзелеш материаллары, ягулык һәм башка матди ресурсларны үз эченә ала.

3. Балтач муниципаль районы территориясендә гадәттән тыш хәлләрне бетерү өчен матди ресурслар резервлары системасы түбәндәгеләрне үз эченә ала:

җирле резерв - муниципаль характердагы гадәттән тыш хәлләрне бетерү өчен Балтач муниципаль районы резервы;

объект резервлары - объект территориясендә гадәттән тыш хәлләрне бетерү өчен предприятиеләр, учреждениеләр һәм оешмалар резервлары.

II. Матди ресурслар резервын булдыру, саклау, файдалану һәм аны тулыландыру тәртибе

4. Гадәттән тыш хәлләрне бетерү өчен матди ресурслар резервларының номенклатурасын һәм күләмнәрен билгеләү, шулай ук күрсәтелгән резервларны булдыруны, саклауны, алардан файдалануны һәм аларны тулыландыруны контрольдә тоту аларны булдырган орган яисә оешма тарафыннан гамәлгә ашырыла.

5. Табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрне бетерү өчен матди ресурсларның җирле резервына продукция китерүне тәэмин итүчеләрне сайлап алу «Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү

өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән тәртип нигезендә гамәлгә ашырыла.

6. Табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрне бетерү өчен матди ресурслар резервларын формалаштыру гадәттән тыш хәл янаган яисә килеп чыккан очракта оешмалар белән тиешле товарларны китерүгә килешүләр төзү юлы белән гамәлгә ашырылырга мөмкин.

7. Табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрне бетерүгә җирле резерв булдыру өчен матди ресурслар заказчысы булып Балтач район башкарма комитеты тора.

8. Гадәттән тыш хәлләрне бетерү өчен матди ресурслар резервлары аларны саклау өчен билгеләнгән, гадәттән тыш хәлләр зоналарына оператив китерү мөмкин булган объектларда урнаштырыла.

9. Табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрне бетерү өчен матди ресурслар резервлары түбәндәгеләр өчен кулланыла:

- торак-коммуналь хуҗалык объектларында, социаль өлкә объектларында һәм башка объектларда кешеләр гомеренә һәм сәламәтлегенә турыдан-туры куркыныч янауны бетерү буенча авария-коткару һәм башка кичектергесез эшләр уздыру өчен;

- зыян күргән гражданнарның вакытлыча яшәү һәм туклану пунктларын җәелдерү һәм аларны карап тоту;

- халыкка бер мәртәбә матди ярдәм күрсәтү;

- зыян күргән халыкның тормышын тәэмин итүгә бәйле башка беренче чиратта кирәкле чараларны үткәрү.

10. Гадәттән тыш хәлләрне бетерү өчен матди ресурслар резервларын куллану, шул исәптән:

а) матди чараларның җирле резервын, шул исәптән: азык-төлекне, әйбер мөлкәтен, беренче чиратта кирәкле предметларны, нефть продуктларын, медицина мөлкәтен һәм медикаментларны, шулай ук төзелеш материалларын һәм башка матди ресурсларны куллану Балтач муниципаль районының гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү комиссиясе күрсәтмәләре нигезендә гамәлгә ашырыла;

б) матди чараларның объект резервлары - оешмалар администрацияләре билгеләгән тәртиптә.

11. Локаль характердагы гадәттән тыш хәлләр барлыкка килгәндә, аларның нәтиҗәләрен бетерү өчен объект резервлары кулланыла. Үз акчалары җитмәгәндә, предприятиеләр, учреждениеләр тарафыннан таләп ителә торган ресурсларның күләмнәрен һәм номенклатурасын нигезләп, матди ресурсларның резервлары исәбеннән ярдәм күрсәтү турында югарырак органнарга заявка тапшырыла.

Муниципаль характердагы гадәттән тыш хәлләр килеп чыкканда, аларны бетерү өчен Балтач муниципаль районы резервларының матди ресурслары файдаланыла. Алар җитәрлек булмаганда, Балтач муниципаль районының җирле үзидарә органы матди ресурсларның республика

резервыннан акча бүлеп бирү турында үтенеч белән Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына мөрәҗәгать итә.

Муниципаль һәм муниципальара характердагы гадәттән тыш хәлләрне бетерү һәм зыян күргән халыкның тормыш эшчәнлеген тәэмин итү өчен Гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү комиссиясе, аларны булдырган органнар һәм оешмалар белән килештереп, матди ресурсларның объект резервларыннан файдаланырга мөмкин.

12. Гадәттән тыш хәлләрне бетергәндә тотылган матди ресурсларның җирле резервын тулыландыру алар мәнфәгатьләрендә файдаланган оешмалар акчалары хисабына яисә тиешле органнар карары буенча башка акчалар хисабына башкарыла.

## III. Матди ресурслар резервларын булдыру, саклау, алардан файдалану, аларны тулыландыру чыгымнарын финанслау

13. Гадәттән тыш хәлләрне бетерү өчен матди ресурслар резервларын булдыру, саклау, алардан файдалану, аларны тулыландыру чыгымнарын финанслау тиешле резервларны булдыручы органнар, оешмалар акчалары хисабына гамәлгә ашырыла.

14. Гадәттән тыш хәлләрне бетерү өчен матди ресурслар резервлары гадәттән тыш хәлләр барлыкка килү мөмкинлеге булган зонадагы предприятиеләрнең һәм оешмаларның иминият фондлары акчалары исәбеннән һәм бюджеттан тыш чыганаклар исәбеннән финансланырга мөмкин.

15. Гадәттән тыш хәлләрне бетерү өчен матди ресурслар резервлары продукциясен сатып алуга кирәкле финанс чаралары күләме матди ресурсларга базар бәяләренең үзгәрү мөмкинлеген, шулай ук резервларны булдыруга, урнаштыруга, саклауга һәм тулыландыруга бәйле чыгымнарын исәпкә алып билгеләнә.

## IV. Матди ресурсларның җирле резервын булдыруны, саклауны, алардан файдалануны һәм аларны тулыландыруны исәпкә алу һәм контрольдә тоту тәртибе

16. Гадәттән тыш хәлләрне бетерү өчен матди ресурсларның җирле резервын булдыруны, саклауны, алардан файдалануны һәм аларны тулыландыруны исәпкә алуны һәм контрольдә тотуны түбәндәгеләр гамәлгә ашыра:

- Балтач район башкарма комитетының икътисад бүлеге - азык-төлек, әйбер мөлкәте, беренче чиратта кирәкле предметлар буенча;
- Балтач район башкарма комитетының төзелеш, архитектура һәм ТКХ бүлеге - төзелеш материаллары һәм җайланмалар буенча;

17. Җирле резервны һәм матди ресурсларның объекттагы резервларын туплауны, саклауны, яңартып торуны оештыруны контрольдә тотуны

«Балтач муниципаль районы Гражданнарны яклау идарәсе» муниципаль казна учреждениесе гамәлгә ашыра.

Татарстан Республикасы
Балтач район башкарма комитетының
2022 елның «16» 07
217 номерлы карарына
2 нче кушымта

Балтач муниципаль районының табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрен бетерү өчен матди ресурслар номенклатурасы һәм күләме

| № т/б | Матди ресурслар исеме | Берәмлек Үлчәү | Планлаштырылган күләмнәр |
|---|---|---|---|
| **1** | **2** | **3** | **4** |
| **1.** | **Азык-төлек,<br>шул исәптән (50 зыян күрүче кешегә + 50 коткару хезмәте хезмәткәренә 3 тәүлеккә исәпләгәндә)** | | |
| 1. | 1 нче сортлы арыш һәм бодай катнашкан оннан икмәк | кг. | 90 |
| 2. | 1 нче сортлы бодай онынннан икмәк | кг. | 105 |
| 3. | 1 нче сортлы бодай оны | кг. | 15 |
| 4. | Сыер мае | кг. | 13,5 |
| 5. | Үсемлек мае | кг. | 9 |
| 6. | Ит яки ит консервалары | кг. | 25 |
| 7. | Балык консервлары | кг. | 11 |
| 8. | Каты сыр | кг. | 3 |
| 9. | Төрле ярмалар һәм макароннар | кг. | 45 |
| 10. | Шикәр | кг. | 13,5 |
| 11. | Чәй | кг. | 0,3 |
| 12. | Бәрәңге, яшелчә һәм җиләк-җимеш | кг. | 270 |
| 13. | Җимеш һәм җиләк соклары | литр | 3 |
| 14. | Тоз | кг. | 6 |
| 15. | Шырпы | кап | 50 |
| 16. | Коры сөт, сөт консервалары | кг./шт. | 30 |
| 17. | Йомырка | данә | 300 |
| 18. | Киптерелгән җиләк-җимеш (йөзем, күрәгә, кара җимеш) | кг. | 3 |
| 19. | Балалар ризыгы | кг. | 5 |
| 20. | Коры паек | к-т | 150 |
| **2.** | **Әйбер мөлкәте һәм яшәүне тәэмин итү ресурслары** | | |
| 1. | Унификацияләнгән көнкүреш палаткасы | к-т | 1 |
| 2. | Каркас тибындагы җәйге солдат палаткасы | к-т | 1 |

| № т/б | Матди ресурслар исеме | Берәмлек Үлчәү | Планлаштырылган күләмнәр |
|---|---|---|---|
| **1** | **2** | **3** | **4** |
| 3. | Медицина палатасы (ПМК) | к-т | 1 |
| 4. | Җылыту җиһазлары (рефлекторлар, радиаторлар, каты һәм сыек ягулык белән эшләүче мичләр) |данә | 3 |
| 5. | Савыт-саба (кружка, кашык, тәлинкә) | к-т | 50 |
| 6. | Караватт (шул исәптән җәелмәле) | данә | 50 |
| 7. | Матрац | данә | 50 |
| 8. | Мендәр | данә | 50 |
| 9. | Йон яисә киҗе-мамык одеял | данә | 50 |
| 10. | Җәймә | данә | 100 |
| 11. | Мендәр тышы | данә | 50 |
| 12. | Сөлге | данә | 50 |
| 13. | Күн, резин, киез һ. б. аяк киеме (шул исәптән 30% балаларныкы) | к-т | 50 |
| 14. | Кышкы җылы кием (шул исәптән 30% балалар киеме) | к-т | 50 |
| 15. | Баш киемнәре, җылы, җәйге | кг. | 57 |
| 16. | Хуҗалык сабыны | кг. | 300 |
| 17. | Керосин яктырткыч | литр | 40 |
| 18. | Стеарин шәме | данә | 100 |
| 19. | «Ярканат» фонаре | к-т | 20 |
| 20. | Коткаручылар өчен махсус кием (кышкы, җәйге) | к-т | 50 |
| 21. | Бияләйләр, эш перчаткалары , җылы | к-т | 50 |
| **3.** | **Төзелеш материаллары** | | |
| 1. | Цемент | тн. | 2,5 |
| 2. | Ылыслы төр агач материаллары 1 сорт 30 х 150 | куб.м | 15 |
| 3. | Ылыслы төр агач материаллары 1 сорт 50 х 150 | куб.м | 16 |
| 4. | Төзелеш комы | тн. | 10 |
| 5. | ПГС | тн. | 15 |
| 6. | Вак таш М1200, фракция 20-40 | тн. | 10 |
| 7. | Кирпеч | данә | 3360 |
| 8. | Профнастил С21, калынлыгы 0,55 | кв.м | 1000 |
| 9. | Түбә саморезлары, 4,8 х 51 | данә | 6500 |
| 10. | Пароизоляция (изоспан), 70 кв.м. | рул. | 15 |
| | | | |

| № т/б | Матди ресурслар исеме | Берәмлек Үлчәү | Планлаштырылган күләмнәр |
|---|---|---|---|
| **1** | **2** | **3** | **4** |
| **4.** | **Нефть продуктлары, шул исәптән:** | | |
| 1. | Автомобиль бензины АИ - 92 | тн. | 3 |
| 2. | Дизель ягулыгы | тн. | 2 |
| 3. | Карбюратор двигательләре өчен автомобиль мае | кг. | 200 |
| 4. | Дизель двигательләре өчен автомобиль мае | кг. | 200 |
| **5.** | **Медицина мөлкәте һәм медикаментлар** | Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан билгеләнә | |
| **6.** | **Башка матди ресурслар** | | |
| 1. | "Ребир" моторлы пычкы | данә | 1 |
| 2. | Тростан ясалган катлаулы чыгыр | данә | 1 |
| 3. | Газ белән эретеп ябыштыру җиһазлары җыелмасы | данә | 1 |
| 4. | Су көче белән эшли торган (гидравлик) домкрат | данә | 1 |
| 5. | Слесарь инструментлары җыелмасы | данә | 1 |
| 6. | Дисклы электр пычкысы | данә | 1 |
| 7. | Тагылма кыр кухнясы | данә | 1 |
| 8. | Пневматик һәм электромеханик приводлы кече механизация чаралары (бораулар, перфораторлар, шомарту машинкалары һ. б.). | к-т | 1 |
| 9. | Шанец коралы (балталар, ломнар, багорлар, пычкылар, көрәкләр, шлямбурлар, кадак суыргычлар, келәшчә) | к-т | 1 |
| 10. | Термос ТВН-12 (метал. 3л.) | данә | 2 |
| 11. | Беркеткеч (скоба), кадаклар | кг. | 700 |
| 12. | Изолятор | данә | 5 |
| 13. | Янмый торган электр үткәргеч | м. | 335 |
| 14. | Үткәргеч (А-35) | кг. | 85 |
| 15. | Түбән вольтлы энергия бирү кабеле (1 КВт) | м. | 85 |
| 16. | Энергия бирү трансформаторы (100 А) | данә | 1 |
| 17. | Эликтролитсыз корылган аккумулятор 6 ст. 75 А. | данә | 1 |
| 18. | Гражданнар противогазы ГП-7 | данә | 50 |
| 19. | Саклагыч костюм Л-І (ОЗК) | к-т | 50 |

| № т/б | Матди ресурслар исеме | Берәмлек Үлчәү | Планлаштырылган күләмнәр |
|---|---|---|---|
| **1** | **2** | **3** | **4** |
| 20. | Изоляцияли торган противогаз ИП-4 | данә | 10 |
| 21. | Регенерация патроны РП-4 | данә | 20 |
| 22. | Электр тавыш көчәйткече (мегафоны) | данә | 1 |
| 23. | Автомобиль радиостанциясе | к-т | 1 |
| 24. | Күчерелмә электростанция 8 КВт | к-т | 1 |
| 25. | Резин көймәләр | данә | 8 |
| 26. | Баулар (100 м) | данә | 16 |
| 27. | Коткару түгәрәкләре | данә | 32 |
| 28. | Коткару жилетлары | данә | 32 |